ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2023 г. Казань № 834-8/нпс-2023

Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне билгеләү турында

«Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 27.12.2023 №65-ПР утырышы беркетмәсенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь чик бәяләр әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне билгеләү турында» 18.07.2014 №9-1/нпс карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.12.2023 № 834-8/нпс-2023
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь дәрәҗәдә чик бәяләр

Бәяләр өстәмә хак салымын исәпкә алып, сумнарда

| т/с | Түбәндәгеләр өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре | Шәһәр торак пунктларында | Авыл торак пунктларында | Торак пунктлар чикләреннән тыш |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару | 10 869 | 10 540 | 11 423 |
| 2. | Шәхси торак төзелеше | 10 869 | 10 540 | 11 423 |
| 3. | Шәхси гараж төзелеше | 10 523 | 10 194 | 11 077 |
| 4. | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы | 10 696 | 10 367 | 11 250 |

Искәрмә.

1. Кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне оештыру-хокукый формаларына карамастан Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләрен башкаручы барлык юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар куллана.

2. Бәяләр максималь дәрәҗәдә чик булып тора һәм кадастр эшләрен башкаручы юридик зат яки шәхси эшкуар карары буенча киметелә ала.

3. Кадастр эшләренең максималь чик бәяләре бер җир кишәрлегенә карата исәпләнгән һәм гражданнар (физик затлар) тарафыннан кадастр эшләренә түләгәндә кулланыла.

4. Кадастр эшләренең нәтиҗәсе булып ызанлау планы тора.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге